**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

**КАРАРы**

28 февраль 2023 ел № 4 Урыссу ш.т.п.

«Башнефть» АНК ГАЖ объекты буенча территорияләрне: 13571 ««Ютаза» ПИК «Добыча» (Туймазанефть) 45-01 ПС 110/6 кВ номерлы фидерны реконструкцияләү планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 14.03.2022 ел, №58-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Территорияне, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын, капиталь төзелеш объектларын төзүгә, файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү документларын әзерләү, килештерү, раслау, гамәлдә булу срокларын озайту үзенчәлекләре турында” 02.04.2022 ел, № 575 карары белән, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгының 23.01.2023 ел «Башнефть АНК ААҖ объекты буенча территорияне планлаштыру һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында» № 5 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Димтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Башнефть» АНК ГАЖ объекты буенча территорияләрне: 13571 «Ютаза» ПИК «Добыча» (Туймазанефть) 45-01 ПС 110/6 кВ номерлы фидерны реконструкцияләүнең планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында ачык тыңлауларның №1 беркетмәсен һәм Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 28 февраленнән булган «Башнефть» АНК ГАЖ объекты буенча территорияләрне: 13571 ««Ютаза» ПИК «Добыча» (Туймазанефть) 45-01 ПС 110/6 кВ номерлы фидерны реконструкцияләүне планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Димтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Башнефть» АНК ГАҖ объекты буенча территорияләрне: 13571 ««Ютаза» ПИК «Добыча» (Туймазанефть) 45-01 ПС 110/6 кВ номерлы фидерны реконструкцияләүне планлаштыру һәм ызанлау проектын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Экология һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы рәисе А.Ә. Шәфигуллин